КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 ноябрь г.Казань № 1012

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 август, 566 нчы карары белән расланган Төбәк һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләш-терелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 16 август, 566 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 октябрь, 1015 нче, 2023 ел, 26 апрель, 529 нчы, 2024 ел, 09 август, 635 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Төбәк һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләш-терелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта «2009 елның 15 июлендәге 569 номерлы» сүзләрен «2024 елның 25 апрелендәге 530 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «2009 елның 15 июлендәге 569 номерлы» сүзләрен «2024 елның 25 апрелендәге 530 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин